| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЗЕЛЕНОРОЩИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЗЕЛЕНАЯ РОЩА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

**2022 елның 1 июне** **№ 12**

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлеге Советының 2013 елның 28 октябрендәге 17/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 6 апрелендәге «Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 608 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлеге Советының 2013 елның 28 октябрендәге 17/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1 статьяның егерме бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күпфатирлы йорт дип Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясының 6 өлешендә билгеләнгән билгеләргә туры килә торган бина таныла».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зеленая Роща авылы, Төзелеш ур., 1 йорт, Мингәрәев исемендәге АКЦ бинасы, Спиридоновка авылы, Совет урамы, 32 нче йорт Спиридоновка авыл клубы бинасы адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Зеленая Роща авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы, Совет рәисе А.А. Потапов